Республика Татарстан
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул.Ахмадиева, д.26, п.Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-99, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы, 423368
Телефон: (85559) 31-0-99, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОКПО 93068410, ОГРН 1061687003069 ИНН/КПП 1636005574/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

22.01.2016 ел — №1

**Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары регистрын алып баруны оештыру мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43.1 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында «Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 9 апрелендәге № 21-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгы белән төзелгән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында 21.01.2016 ел килешүе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча үзара хезмәттәшлеге 20.01.2016 года №14 регламентына таянып эш итәргә.

муниципаль район Советына муниципаль район Башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларын җибәрү өчен җаваплы затларны, шулай ук алар турында регистрга кертелергә тиешле белешмәләрне билгеләргә;

регистрны оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка чаралар күрергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU (Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитеты җитәкчесе Э.Н.Зиангиров